**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Исполнительный комитет
Чубар-Абдулловского
сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Советская, д.81, с.Чубар-Абдуллово, 423323
Тел. (8-85592) 38-7-30, 38-7-37

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

Азнакай муниципаль районы
Чубар-Абдул авыл жирлеге
башкарма комитеты

Совет урамы, 81, Чубар-Абдул авылы, 423323
Тел. (8-85592) 38-7-30, 38-7-37

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«07» сентябрь 2018 ел № 14

Референдум уздыруны инициацияләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чубар-Абдул авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, карар бирәм:

1. Түбәндәге сорау буенча җирле референдум уздыруны инициацияләргә:

"Сез, 2019 елда Чубар-Абдул авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә, көндезге формада белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

2) җирлек халкының күпләп ял итүе өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карар түбәндәгеләргә урнаштыру юлы белән халыкка игълан ителергә тиеш:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының түбәндәге адрес буенча урнашкан Чубар-Абдул авыл җирлегенең мәгълүмат стендлары:

ТР, Азнакай муниципаль районы, Чубар-Абдул авылы, Совет ур., 85. ТР, Азнакай муниципаль районы, Октябрь ур., Буралы авылы, 34 йорт авыл мәдәният йорты янында, ТР, Азнакай муниципаль районы, Ялантау урамы, 36б йорт, авыл мәдәният йорты янында – түбәндәге веб-адрес буенча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы: http://pravo.tatarstan.ru, адресы буенча;

- Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында түбәндәге веб-адрес буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http://aznakaevo.tatarstan.ru урнаштырырга.

Башлык Н.А.Фәтхетдинов